СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22. 03. 2024 г.Лениногорск № 10

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 17 октябрендәге 66 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 19 декабрендәге 613-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 17 октябрендәге 66 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

19 статьяның 3.3 өлешендә «3 – 6 пунктлары» белән сүзләрен «3 – 5 пунктлары» белән сүзләренә алыштырырга;

29 нчы статьяның 29.3 нче өлешендәге 10нчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зиратларны, терлекләр каберлекләрен, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру объектларын, химик, шартлаткыч, токсик, агулы һәм агулаучы матдәләрне (исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган диңгез портлары территорияләрендәге аммиак, метанол, аммиак селитрасы һәм калий нитраты махсус саклагычларын исәпкә алмаганда, яр буе саклау полосалары чикләреннән тыш), радиоактив калдыкларны күмү пунктлары, шулай ук балык хуҗалыгы әһәмиятендәге су объектларында рөхсәт ителгән чик концентрацияләре билгеләнмәгән территорияне пычратучы матдәләр белән пычрату;».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында

(http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов